

Рузаевка районындагы «Турбиналар традициясе» гаилә умарталыгында тәҗрибәле умартачы, 1 класслы машинист Александр белән ярдәмче хуҗабикә Ирина Турбиннар, сәяхәткә килгән кунакларга умарталар тормышыннан кvп серләр ачалар: кем умартада баш, ни очен гаиләдә трутни, патша-аналык (королева-матка) һәм ин кечкенә бал кортларын ничек танып була. Алар Мордовиядән һәм башка регионнардан килгән кунакларга экскурсияләр vткәрәләр.      Шулай ук монда сәламәтлек очен уникаль продуктлар житештерәләр: аналык соте, трутневый гомогенат, перга, бальзамнар белән бал кортлары агуы һәм, әлбәттә, бал vзе. Туристларга чәй эчv һәм бал татып карау тәкъдим ителә. Сорау буенча квест яки шәмнәр ясау буенча мастер-класс оештырырга момкиннәр. Ял итvне тирә-яктагы матур табигать матур урман һәм матур буа тулыландыра. Умарталык территориясендә Себер мунчасы бар. Агротуризмны алар хокvмәт гранты ярдәмендә жәелдереп жибәрәләр.
- Участок земли, на котором теперь наш «филиал», мы купили год назад, - ди Ирина Турбина. - Новое место для пчел - это первый шаг к нашей мечте - развитию агротуризма, в осуществлении которой вызвалось оказать нам грантовую поддержку государство. Облюбовали самый крайний к пруду и ближний к лесу участок. Скоро пасека традиций Турбиных будет не только поставщиком меда и продуктов пчеловодства, но и классным пространством для отдыха всей семьей.
Ә кем сон алар Турбиннар? Умарталыкта баш умартачы Александр vзе, анын хатыны Ирина - ярдәмдә. Ирле-хатынлы бал кортлары турындагы фән шулкадәр кызыклы һәм кин, аны гомер буе анларга кирәк, диләр. Һәм vз умарталыгында гына тvгел, ә Рыбный шәһәрендәге Федераль умартачылык фәнни vзәгендә дә Александр белән Ирина кvптән инде “vзенекеләр” булып киткәннәр. Алар һәрвакыт курсларга йориләр, анда уку аларга бал кортлары фәнендә яна нәрсәләрдән хәбәрдар булырга момкинлек бирә. “Без федераль vзәктә алган белем бик кыйммәтле”, - ди Ирина ханым.
Турбиннар гаиләсендә оч ул vсә, аларнын ин олысына 14 яшь. Ирина университетта икътисад факультетын тәмамлый һәм vз вакытында тимер юлда эшли, әмма инде берничә ел vзен улларын тәрбияләvгә һәм гаилә умарталыгына гына багышлый. Олы уллары Маркнын тумыштан ук булган авыруы Турбиннарны умартачылык хоббиеннан яраткан эшләренә әйләнергә этәрә. Александр нәселле умартачылар гаиләсеннән, алар бал кортларына бер гасыр багышлыйлар. Ул vзе дә алты яшеннән колхоз умарталыгында әтисе белән эшли. Ә 14 яшендә 120 умартадан торган умарталыкта умартачы ярдәмчесе була. Александр умартачы булыр иде, ләкин ул тимер юл транспортында эшләvне сайлаган. Бал кортларына хатыны Иринага да кайтырга улларынын авыруы мәжбvр итә; авыруы алдында традицион медицина кочсез булып чыга. Ата-аналарнын бәхете балаларнын сәламәтлегендә бит. Балалар авырса, донья байлыгы кирәк тvгел. Шулай, 2020 елда Александр да моһим һәм ихтыярлы карар кабул итеп, бал кортларына кайта. Александр белән Ирина vз умарталыгын булдыра башлыйлар. Нигез итеп олкән Турбиннын берничә сакланып калган бал кортлары гаиләсен алалар. Башлаган эшләрен жәелдерv очен аларга банк кредитын алырга туры килә, хәтта машиналарын да саталар.

Тырышлыклары бушка булмый. Бvген 50 гаиләдән торган умарта продукциясе базарда тәкъдим итәр очен житәрлек. Турбиннар клиентлары белән аралашалар, консультация бирәләр, һәркемгә аерым якын килеп жавапны сайлыйлар. Бvген алар халыкка булышылар һәм Махсус хәрби операциядә катнашучыларга да умарта яды белән ясалган бальзам жибәрәләр.

**Н.ХӘЛИЛ**